СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2022 г.Лениногорск № 65

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2022 елның 31 октябреннән 2022 елның 21 ноябренә кадәр үткән ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (parvo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы вазифаларын башкаручы О.С. Глуховага йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов